РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
02 июн 2024ел.

КАРАР
№ 310

**Әтнә район башкарма комитетының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әтнә район башкарма комитеты карар итә:

1. Әтнә район башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

15.02.2021 №34 “Аукцион үткәрмичә муниципаль милектә булган җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”;

21.07.2021 №260 “Җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитут, иҗтимагый сервитут билгеләмичә дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрне яки җир кишәрлекләрен файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”;

30.09.2021 №410 “Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын арендалау шартнамәләре буенча торак урыннар бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкчесе А. Ф. Каюмов